Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

# КАРАР

26 март, 2024 ел №12

Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Комар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставы нигезендә, Оштырма Юмья авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2024 елның 06 апрелендә 10 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы Яңа Комар авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Яңа Комар авылы, Урман урамы, 3 нче йорт адресындагы торак йорт янында үткәрергә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлегенең Яңа Комар авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарына түбәндәге мәсьәлә буенча үзгәрешләр кертүгә ризамы: «Сез 2024 елда Кукмара муниципаль районының Оштырма-Юмья авыл җирлеге Яңа Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә катнашучы контракт хезмәте хәрбиләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм

алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Яңа Комар авылының Урман урамы, Яшьләр урамында юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү;

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү, Яңа Комар авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавлары, стволлары, күчергечләре, колонкалары, мотопомпалары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- Яңа Комар авылында суүткәргеч системасын, су суырту манарасын, скважиналарны һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту һәм төзекләндерү, кул белән һәм экскаватор белән туфрак эшкәртү, торба үткәргеч салу, ремонтлау, су суырту манарасы өчен бетон боҗралар, капкачлар һәм люклар, насос сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, экскаватор һәм манипулятор хезмәтләре өчен түләү, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

- урам яктырту җайланмасы, урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү;

территорияне төзекләндерү, яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

2023 елның 30 ноябрендәге 1 номерлы карарында күрсәтелгән эш төрләрен үзгәртү өлешендә түбәндәге эшләр белән:

- тышкы урам яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм аларга бирелгән башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау(урам яктыртуны карап тоту, комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, урамнарны яктыртуны карап тоту буенча башка эш төрләре, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру);

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су суырту манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган инженерлык корылмалары төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү системаларын, су саклау зоналарын, су суырту манараларын, артезиан

скважиналарын һәм башка инженерлык челтәрләрен ремонтлау, карап тоту, төзекләндерү, бетон бождралар, капкачлар һәм люклар, артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу, эш өчен шартнамә буенча түләү, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Яңа Комар авылында су белән тәэмин итүне, су саклау зоналарын һәм су суырту манараларын карап тоту буенча башка эш төрләре);

- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту (территорияне төзекләндерү, яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту, яр буен ныгыту, яр буе зоналарын һәм сулыкларны чистарту буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү Яңа Комар авылында янгын гидрантларын, янгын сүндерү рукавларын, стволларны, күчермәләрне, колонкаларны, мотопомпаларны карап тоту, сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, Яңа Комар авылында янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча башка эш төрләре);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту Яңа Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту, кышын юлларны кардан чистарту һәм җәен территорияне чабу, төзекләндерү; трактор һәм чапкыч өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, юл челтәрен карап тоту буенча башка эш төрләре); (Яңа Комар авылының Урман урамы, Яшьләр урамында юлларны төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, җәю, суүткәргеч торбалар урнаштыру, шартнамә буенча эш өчен түләү, юлларны карап тоту һәм төзекләндерү буенча башка эш төрләре).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Оштырма Юмья авыл җирлеге Уставында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Оштырма Юмья авыл
җирлеге башлыгы: С.В.Тимофеев